**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Салманского сельского поселения Алькеевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**
**Салман авыл җирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Адрес: 422874, РТ, с. Салманы ,
ул. Молодёжная, 12
тел: 8 (84346) 72-2-38

Адресы: 422874, РТ, Салман авылы,
Яшьлер ур., 12
факс: 8 (84346) 72-2-38

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Салман авылы **КАРАР**

2024 елның 16 мае 1№

Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 23 августындагы "Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтеры һәм бухгалтерларының хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турында" 32 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Әлки муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаучы аерым бюджет оешмаларының үзәкләштерелгән бухгалтерияләре хезмәткәрләренә социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм хезмәт өчен түләүне тәртипкә салу максатларында, Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 23 августындагы "Бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренең профсоюз органы фикерен исәпкә алып, Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтеры һәм бухгалтерларының хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмә" 32 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

| Вазыйфа | Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетларындагы халык саны | |
|---|---|---|
| | 3,5 меңгә кадәр кеше | 3,5 меңнән артык кеше |
| Баш хисапчы | 23 700 | 25 000 |
| Хисапчы | | 22 500 |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми http://pravo.tatarstan.ru порталында бастырырга.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Киңәшләшкән:
хезмәткәрләр вәкиле

_______________Яшина Л.Л.
(Ф. И. О.)

Әлки муниципаль районы Салман
Башкарма комитет җитәкчесе

_______________И.В.Юсупов